

Леонид Иванович Воинов 1898 елнын 12 июнендә Темников - vзенен кабатланмас йозе, бай тарихы, vзенчәлекле тормыш рәвеше һәм мәдәни традицияләре булган шәһәрдә туган. Анда яшvсмер еллары һәм анын ижат шәхесенен формалашуы уза.
Музыкага һәм рус балалайкасына мәхәббәт Темник гимназиясендә укыганда vзен сиздерә. Ул чакта яшьләр арасында музыка белән мавыгу гимназия житәкчелеге һәм, барыннан да элек, аныn директоры А.В. Чикунский тарафыннан яклау тапкан. Ул рус кыллы оркестры инструментлары комплекты сатып ала, гимназистларны музыкаль грамота һәм жыр нигезләренә ойрәтv очен Петербургтан музыка укытучысы П.В. Беляевны чакыра. Л.И.Воинов инициативасы белән гимназиядә һәвәскәрләр оркестры оештырыла. 1917 елда, гимназияне тәмамлаганнан сон, Леонид Иванович - Казан университетынын тарих - филология факультеты студенты. Революциядән сон ин моһим жайланмаларнын берсе - яна тынлаучыга, рухка һәм заман таләпләренә жавап бирvче музыкага юнәлеш бирv. Аерым энтузиаст-музыкантлар тырышлыгы белән һәр жирдә хор һәм оркестр коллективлары, халык театрлары, музыка студияләре һәм тvгәрәкләр оештырыла. Ил һәм һәр кеше очен хәлиткеч һәм катлаулы вакытта Воинов университетны калдырырга һәм туган ягына кайтырга карар кабул итә. Ул беренче адымнарыннан ук Темникта Совет властен урнаштырудагы мәдәни фронт хезмәткәрләре арасына актив керешә. Инициатива һәм конләшерлек vжәтлек кvрсәтеп, Леонид Иванович рус халык уен коралларынын vзешчән оркестрын оештыра. 1918 елнын 20 мартында оркестрнын «Смело, товарищи, в ногу!» дигән жыр белән башлана. 1923 елдан башлап Л.И.Воинов шәһәр мәктәпләрендә һәм педагогия училищесында музыка укытучысы булып эшли. Бер vк вакытта оркестр, хор һәм солистлар белән шогыльләнә, музыка ижат итә. Шулай итеп, 1924 елда ул vзешчән артистлар коче белән Пушкин сюжетына «Сказка о Попе и работнике его Балде» операсын яза һәм куя.
Леонид Ивановичнын музыкаль vсештә, композитор һәм башкару осталыгын камилләштерvдә кvренекле музыка эшлеклеләре - А.Б.Гольденвейзер, Б.С.Трояновский, В.В.Андреев исемен-дәге рус халык уен кораллары оркестры музыкантлары белән дуслык һәм ижади элемтәләр зур. Анын биографиясендә мордва фольклорына игътибар итәргә кинәш биргән композитор Л.П.Кирюков белән очрашу яна ижат этабы булды.
XX гасырнын 40 нчы елларыннан башлап Мордовия мелосы Л.И.Воинов ижатынын ныклы таянычы була. Башка әсәрләр арасында оркестр белән балалайка очен ике концерт,

оркестр очен ике мордва темасына фантазия - «Мордовская рапсодия», «Мордовский марш», кантатлар - «Сказ о Мордовии» белән «Край родной» һәм мордва халык жырларын эшкәртv очен фантазияләр язган. Оркестр репертуарында - рус һәм Конбатыш Европа классикасынын анын житәкчесе тәржемәсендәге иншалары. Оркестр белән танылган жырчылар - И.М.Яушев, А.В.Яшнов, И.М.Скобцов, М.Н.Ан-тонова, Р.М.Беспалова, Д.И.Еремеев чыгыш ясадылар. Бvген Темников оркестры vзенен оештыручысынын һәм житәкчесенен исемен йортә. Бу коллектив Мордовия Республикасы Дәvләт премиясе лауреаты, тобәкара һәм республика фестивальләребелән конкурслары лауреаты һәм дипломанты.
Композитор 1967 елнын 29 октябрендә Саранскида вафат була. Мордва музыка сәнгатен vстерv олкәсендәге хезмәтләре очен Л.И.Воиновка МАССРнын халык артисты (1947) һәм РСФСРнын атказанган сәнгать эшлеклесе (1960) исемнәре бирелде. Темниковтагы сәнгать мәктәбе белән Саранскрагы 4-нче номерлы балалар музыка мәктәбе Л.И.Воинов исемен йортәләр. Анын исеме белән Темников һәм Саранск урамнары да аталган.

**Н.Хәлил**
*Рәсемдә: Темниковтагы Л.И.Воинов мемориаль музей-йорты*